

ISSN 0868-4545



Сałават күпере



Игътибар! Бәйге дәвам итә!

Шүрәле малае Шүркә



Шамил төшкән чокырга

Шамил урманга киткән,
Тиз генә барып җиткән.
«Шүркәне тотам, – дигән, –
Бик нык куркытам!» – дигән.

Шүркә дә тик ятмаган,
Урман юлын таптаган.
Берничә тозак куйган,
Үзенчә план корган.

Ялкаулык һәм наданлык –
Шүркәнең дошманнары;
Шамилдәге сыйфатларга
Эче бик пошкан аның.

Уйлый Шүркә, уйлана,
Сизми кояш батканны.
Әллә «Урман мәктәбе»ндә
Тиккә укып ятканмы?

Күктә йолдызлар яна,
Күзләрен кыса-кыса.
Шамил батыр куркудан
Агач төбенә поса.

Шүркә корган тозакка
Сизми кала төшкәнен.
Чыгалмыйча, озак торгач,
Аңлый авызы пешкәнен.

Таң аткан да көн булган,
Шулвакыт Шүркә килгән.
Шамил атлы малайга
Ул менә ниләр дигән:

«Көн дә укырга йөрсәң,
Белемле булыйм дисәң,
Мондый хәлгә һичкайчан
Эләгә алмас идең,



Фирүзә ӘСКАРОВА, 10 яшь.
Биектау, Бикнарат.



Фирүзә АВЗАЛОВА, 7 яшь.
Азнакай, Татшуган.

Төне буе караңгыда
Чокыр сакламас идең».

Шамил хәзер үзгәргән ди,
Күп укый, белем ала.
Ул хәзер ялкау түгел –
Тәртипле, тырыш бала.

Зөлфинә ГАЗИЗОВА, 14 яшь.
Гөлфинә ГАЗИЗОВА, 9 яшь.
Сарман, Җәлил.

Бу матур рәсемнәрне Актаныш районы Михайловка башлангыч мәктәбе укучылары ясаган.



Ландыш МӨХӘММӘТҖАНОВА, 10 яшь.



Гүзәл ШӘРИФУЛЛИНА, 8 яшь.



Лиза ПУГАЧЁВА, 9 яшь.



Ленар ГАЛЛӘМОВ, 9 яшь.



Ильяс ГОСМАНОВ, 9 яшь.

Туган җирем – Татарстан

Быел безгә Төркиядән
Бер кунак егет кайтты.
Үзләренең торган җирен
Әй, мактый инде, мактый.

Тыңлап-тыңлап тордым да,
Мин дә сөйләдем әле:
«Безнең Татарстаныбыз
Кайсы илдән ким әле?!

Гөлбакчага тиң бит ул:
Кырлары, урманнары,
Челтерәп аккан чишмәләре,
Болын һәм тугайлары.

Төрле милләт халыклары
Дус, тату яши бездә.
Озак яшәргә язсын
Бу матур җиребездә.

Шулай, дустым, һәркемгә дә
Үзе торган җир якын.
Чит җирләргә китмәс кеше,
Яратса илен, халкын».

Лилия ХӘЙРУЛЛИНА.
Яшел Үзән, 10 нчы гимназия.

Тәмле телле малай

Нәсим көн саен иртә уяна. Шулай гадәтләнгән. Бүген дә, уянуга, урыныннан җәһәт кенә сикереп торды. Борынына шундук тәмле ис килеп керде. «Әби коймак пешерә», дип уйлады ул. Һәм ялгышмады. Нәсим әбисе янына килде.

– Хәерле иртә, әбием!

– Һәй, күрми дә торам, дәү улым уянган икән! – диде әбисе. – Хәерле иртә, улым, хәерле иртә!

– Коймакны тәмле пешерәсең дә инде, әбием. Авызымнан сулар килә – ашамыйча чүт түзеп торам!

– Хәзер ашарсың, балам. Битләреңне, кулларыңны юып кил башта, яме. Әтиең белән әниең, коймактан авыз итеп, эшләренә киттеләр инде.

– Әбием, син безнең авылдагы әбиләрнең иң әйбәте! – диде Нәсим һәм өлкәннәрдән ишеткәнен матур гына итеп өстәде: – Ходай сине саулыктан аермасын!

– Рәхмәт, балам, – диде әбисе. – Сиңа да Ходай һәрчак мәрхәмәтле булсын!

– Әбием, ничек соң, бүген төнлә әйбәт йокладыңмы? Ямьсез төшләр кереп интектермәдеме?

– Сабый бала кебек йокладым, улым. Гел тәмле төшләр генә керде, – диде әбисе.

Нәсим битләрен, кулларын юып килде дә өстәл янына утырды. Күзләрен әле табадагы коймакларга, әле тәлинкәдәгеләргә төшереп алды да:

– Әбием, мин сиңа сокланам. Искиткеч тәмле итеп коймак та, бәлеш тә, өчпочмак та пешерәсең. Барыбызга да җылы оекбашлар, бияләйләр бәйлисең. Маладис син, әбием!

– Бигрәкләр дә тәмле телле инде син, балам. Кемгә охшагансыңдыр?


– Мин сиңа охшаганмын, әбием!


Бераздан әби белән онык, бер-берсенә тәмле сүзләр генә әйтешә-әйтешә, коймак ашарга, чәй эчәргә кереште.


Кадерле дускай!

“Тәмле телле” дигәнне син ничек аңлыйсың? Өлкәннәр белән син шулай матур итеп сөйләшәсеңме? Тагын нинди “тәмле” сүзләр беләсең? Безгә кызыклы хатлар, шигырьләр язып җибәр, яме?









Рәссам Алла АЙСИНА




Мин бит бу?!



– Кабагымны и мактыйлар:
«Бигрәкләр дә зур!» – диләр...
Мин дә зур бит! Тик, нигәдер,
Мине мактый белмиләр.

Балык Бистәсе, Котлы-Бөкәш.



Алсу,
1 яшь 3 ай



Рафаэль, 5 яшь

– И матур кыз, сылу кыз,
Әйдә, танышыйк әле;
Бергә гомер итәрбез –
Әйдә, кавышыйк әле!

Азнакай.


– Ишегалдында йөримен
Сандали киеп кенә...
Син дә, маэмай, сандали ки –
Йөрерсең биеп кенә!

Яшел Үзән, Урысбага.



Гөлназ, 5 яшь





Илһам, 5 яшь

– Ишетсен әле Кыш бабай
Яңа ел теләкләрен:
«Безгә һәр көн алып кил син
Яңа ел бүләкләрен!»

Яшел Үзән, Урысбага.



Гөлсинә, 7 яш
Ильяс, 2 яш

– Карагыз: мин нинди зур!
Чүмечем дә шундый зур...
Аңлагансыздыр инде –
Ашханәдә мин дежур!

Азнакай.



Илназ ИМАМРАЗЫЕВ, 7 яшь.
Актаныш.



Булат НАСЫЙБУЛЛИН, 7 яшь.
Әгерҗе.

Бәхет өчен гаилә кирәк

Бик бәхетле булу өчен
Әни кирәк, әти кирәк.
Безгә күз-колак булырга
Бабай кирәк, әби кирәк.

Энекәшләр, сеңелләр һәм
Апа белән абый кирәк.
Туганнар белән яшәвең,
Әлбәттә, күңеллерәк.

Һәммәбезгә гаилә кирәк:
Олыга да, кечегә дә.
Гаиләле бәхет телим
Һәммә, һәммә кешегә дә.

Рамилә БАТЫРШИНА, 11 яшь.
Яшел Үзән, 10 нчы гимназия.

Кадерен белик

Әтиең, әниең, туганнарың булу
Зур бәхет ул шушы дөньяда.
Татулыкта алар белән торсаң,
Рәнҗетмәсләр сине кайда да.

Бер-беребезнең кадерен белик,
Хөрмәт итик олы-кечене.
Бергәләшеп дөньяларда яшәү –
Шушы олы бәхет түгелме?

Ришат ӘХМӘТШИН, 10 яшь.
Әлки, Иске Салман.




Илүзә ЯМАШЕВА, 9 яшь.
Әгерҗе, Исәнбай.



Айназ ИМАМРАЗЫЕВ, 4 яшь.
Актаныш.

Мөслим районы Вәрәшбаш мәктәбеннән язмалар

Мин бәхетле



Мин үземне бик бәхетле саныйм.Чөнки мин матур гаиләдә яшим. Янымда әти-әнием, әбием, апам һәм энем бар. Алар барысы да мине яраталар. Иртән әниемнең үбеп уятуы, әбиемнең мәктәптән каршы алуы, әтиемнең алып кайткан тәмле әйберләре – болар барысы да минем өчен бәхет.

Ләкин әбием: «Ипекәй – олы бәхет!» – ди. Чыннан да, күктә кояш балкыса, дөньяда тынычлык булса, өстәлдә ипи күпереп торса – олы бәхет була.

Чулпан ГАНИЕВА, 8 яшь.



Бердәмлек кирәк

Минем әтием фермада, әнием клубта эшли. Без бәйрәмнәрне бик күңелле итеп үткәрәбез.

Әнием белән апам Эльвина тәмле ризыклар пешерә. Ә без өстәл әзерлибез.

Гаиләдә татулык, бердәмлек булганда гына матур яшәп була. Мин җир йөзендәге барлык гаиләләргә татулык телим.

Ришат ШӘЙХИНУРОВ, 10 яшь.

Тату яшибез



Безнең гаиләдә 6 кеше. Әнием Рәмилә, әтием Рәдиф, әбием Фатиха, бабам Тәлгать, энем Раил һәм мин Рәилә. Без гаиләдә бик тату яшибез. Әни мәктәптә эшли, әтием механизатор. Әби белән бабай өйдә лаеклы ялда. Энем «Аккош» балалар бакчасына йөри. Минем ерак әбием дә бар. Аның исеме Фәсимә. Минем әле башка туганнарым да бар. Без алар белән бик тату яшибез.

Рәилә БАҺАУОВА, 8 яшь.

Әти-әниемне яратам



Минем әтием Шәйхетдинов Радик Хасбетдин улы «Юлчы» юл төзү идарәсендә эретеп-ябыштыручы булып эшли. Әнием – Шәйхетдинова Люба Василий кызы. Ул элемтә бүлегендә хат ташучы булып хезмәт итә. Әле безнең белән яшәүче эт, песи дә бар. Без аларны бик яратабыз. Мин алар белән гел уйныйм. Мин үземнең әнием белән әтиемне бик яратам, хөрмәт итәм.

Раил ШӘЙХЕТДИНОВ, 8 яшь.

Дусларым да күп

Без гаиләдә 5 кеше яшибез. Абыем Нияз, җиңгәм Эльвира, мин һәм энем Аяз, сеңлем Зәлия. Мин аларны бик яратам. Алар да мине бик яраталар. Без – тату гаилә, бер-беребезне хөрмәт итәбез. Һәр гаиләдә тынычлык, бер-береңне аңлау һәм зур мәхәббәт булырга тиеш.

Минем дусларым да бик күп. Рәилә – иң якын дустым. Ул безнең күршедә генә яши. Без аның белән мәктәпкә гел бергә йөрибез, буш вакытта төрле кызыклы уеннар уйныйбыз, серләшәбез. Дуслар белән дә тату булырга кирәк. Аларны рәнҗетергә, аларга авыр сүз әйтергә ярамый.

Сәламәтлек, татулык булганда гына матур яшәп була.

Регина ЮНЫСОВА, 8 яшь.

Эшләрне бергәләп эшлибез



Минем әтием – Мирзасалих, әнием – Миләүшә, сеңлем – Камилә. Без Вәрәшбаш авылында яшибез. Безнең гаилә бик тату, бер-беребезне хөрмәт итәбез.

Минем дусларым-сыйныфташларым да бар. Без класста бер гаилә булып яшибез. Без эшләрне дә бергәләп эшлибез: ай саен сыйныф бүлмәсен җыештырабыз, яз-көз көннәрендә мәктәп бакчасын чүптән арындырабыз. Ә быелтыр яз көне без утрауга агач утыртырга бардык. Табигать – безнең дустыбыз, шуңа күрә без аны сакларга тиеш.

Дилүс СКАЧКОВ, 8 яшь.

Рәссам Фәрит МУЛЛАХМӘТ



Галимҗан ГЫЙЛЬМАНОВ

«Икеле» – «икеләләр»...

Татар теле укытучысы Вәсилә апа, класс ишегеннән килеп керүгә, ялт итеп Самат ягына карап алды. Малайның йөрәге «жу» итеп китте. «Бетте баш, сораячак икән...» – дип уйлады ул. Шулай булды да. Күрше партадагы кызлардан үткән дәрес темасын сорарга дип авызын ачкан гына иде, такта ягыннан таныш тавыш яңгырады:

– Самат, бас!

Самат торып басты.

– Агач, йорт, сыер сүзләрен күплектә төрләндер әле.

Самат өй эшенең шундый җиңел булуына гаҗәпләнебрәк калды, әмма үзен бик тиз кулга алып, чатнатып җавап бирә башлады:

– Агач – урман, йорт – авыл, сыер – көтү...

– Ничек-ничек?

– Агач – урман, йорт – авыл...

– Туктале, Самат, тукта, тагын бер тапкыр уйлап кара әле. Бер агач бер агач инде ул, ә менә ике, өч, дүрт, күп агач ничек була?

– Урман була, шуны да белмисезмени, апа?

– Ярый, шулай да ди. Ә бу мисал: бер чынаяк тора, аның янында тагын берничәсе тезелеп киткән; шул күп чынаякны бер сүз белән ничек атап булыр иде?

– Ничекме? Ә! Сервиз!

– Һаман үз туксаның туксан!.. Самат, акыллым, менә монда кара – класс бүлмәсенә куелган барлык шкафлар ничек әйтелә инде?

– Гарнитур!

– Юк, Самат, алай булмый! Булмый! Дәресеңә әзер түгел син бүген. Икеле!

– Икеле? Икеле... Ә, апа, белдем-белдем: икеле – икеләләр, өчле – өчләләр, дүртле-дүртләләр...





Иң атаклы елга

Бүген дәрестә «Елгалар» темасы үтелде. Булат бу теманы бик яхшы үзләштерде. Чөнки аларның үзләрендә дә елга бар. Авылны урталай бүлеп ага торган бу елганың исеме кеше исемен хәтерләтә — Илекәй. Җәен-кышын, язын-көзен бөтен авыл баласы шул елга буенда була. Ул — Өчбүлә авылының җаны кебек, җаны ук булмаса да, йөрәге булуы хак та хак инде. Чөнки бөтен үзәнлекләр, көтүлекләр, болыннар, әрәмәлекләр һәм чишмәләр Илекәй елгасы буена урнашкан.

Бервакыт Булат үз авылларын елгасыз гына күз алдына китереп карады. Танымады. Илекәй елгасы булмаса, Өчбүлә авылы бөтенләй икенче авылга әверелер иде, исеме дә бүтәнчә булыр иде. Юк, Илекәйсез Өчбүлә була алмый...

Менә шул. Бүген дәрестә Булатларга Татарстандагы елгалар хакында сөйләделәр. Бездә бөтен дөньяга танылган Идел елгасы, аннары Чулман, Зөя, Ык, Мишә елгалары бар, диделәр, башка бик күп елгаларны телгә алдылар. Соңыннан укытучы апалары сораулар бирә башлады. Булат белә: үтелгән дәресне шулай тикшерә ул. Беренче булып Булаттан сорады:

– Татарстандагы иң атаклы елганы әйт әле, — диде.

Булат ике дә уйлап тормыйча:

– Илекәй! — дип чатнатып җавап бирде.

Укытучы апалары матур итеп елмайды да зур «бишле» куйды. Чөнки җавап дөрес иде.

Рәссам Иван **ВОРОБЬЕВ**



Земфира ГЫЙЛЬМЕТДИНОВА

Асыл пәрәвезле Үрмәкүч



Үрмәкүч кояш чыкканчы ук уянды. Бүген аның эше бик күп шул. Хуҗалары белән кичә генә яңа фатирга күченде ул. Инде хәзер биредәге иң матур почмакта, бик тә затлы пәрәвез үрәсе бар аның. Барлык бүлмәләрне әйләнеп чыккач, пәрәвез-өен кечкенә Азат бүлмәсендә корырга булды ул.

Менә Үрмәкүч җырлый-җырлый пәрәвез үрә, һәр җепселне саный, араларын үлчи, азрак үргәч ныклыгын тикшереп карый. «Матур булсын, хуҗаларыма ошасын. Кояшта җем-җем иткән пәрәвеземне күрсеннәр дә куансыннар», – дип теләк тели-тели эшли Үрмәкүч. Менә аның асыл пәрәвезе инде әзер дә булды. Тәрәзәдән кергән кояш нурларында көмештәй ялтыраган өенә сокланып торды да, бер җепселенә утырып, йоклап яткан кечкенә хуҗасы Азатны уятырга дип төште ул. Тик күзләрен ачып, Үрмәкүчне күргәч, Азат курыкты шул. Аның елаган тавышына әнисе керде. Үрмәкүчкә ачуы килде. Аннан соң бик озын себерке алып, аны асыл пәрәвезе белән бергә урамга чыгарып ташладылар.



Икенче иртәдә Азат бүлмәсенә бик усал черки очып керде. Керде дә: «Без-з-з, без-з-з, сез-з-з-нең кирәгегез-з-з-не бирәбез-з-з!» – дип яный башлады. Кызганыч, малайны бу усалдан сакларга асыл пәрәвез дә, кешеләргә бер зыян да салмаучы, аларны зарарлы бөҗәкләрдән генә яклаучы Үрмәкүч тә юк иде шул инде.

Рәссам Светлана ПРИВИНА



ҮРМӘКҮЧ ДИГӘННӘН...

Җир шарында егерме мең төрдәге үрмәкүч бар.

Үрмәкүчләрнең зурлыгы ярты миллиметрдан алып унбер сантиметрга кадәр булырга мөмкин.

Өй үрмәкүче **тегенария** дип атала. Ул өйгә кергән чебен-черкиләрдән саклый.

Безнең илдә яшәгән үрмәкүчләрнең бер төре дә кешеләргә зыян салмый.

Кешеләр курка торган **тарантул** да, үзенә кагылмасаң, беркемгә кагылмый. Ул тешләгән очракта да җәрәхәтләми. Тешләнгән җир 3-4 көндә төзәлә.

У-У, КУРКЫНЫЧ У...У...УТ!

Кып-кызыл үзе,
Ялтырый күзе.
Ай-яй ул җитез,
Ялмап йота тиз.

(Ут.)

Кайдадыр ут чыгуын хәбәр итсәләр,
чабам юлларда ашыгып.
Теләсә нинди янгынны
көчле кешеләр белән бергә сүндерәм.

(Янгын машинасы.)

Уттан чыгам,
дулап агуландырам.

(Төтен.)

Өе дә пыяла,
тәрәзәсе дә пыяла.

(Лампа.)

Кечкенә генә йорт,
анда ике дистә кеше яши.

(Шырпы.)

Яна-яна, дулый-дулый,
бик тиз һәр нәрсәне җимерә.

(Янгын.)

Янгыннарны сүндерәм,
Кешеләргә булышам.

(Сүндергеч.)

Өйдә янгын чыкса,
Синдә телефон булса,
Шылтыратырга кирәк
Нинди номер буенча?

(01.)

Рәссам Фәрит МУЛЛАХМӘТ

Рөстәм МИНГАЛИМ

Өч Закир һәм аларның өч малае турында

Булса да була бит
шундый кешеләр?!
Әйе, була
шундый кешеләр:
«күкрәкләре
калкан-калкан,
мускуллары
шалкан-шалкан».
гаҗәп көчлеләр!
Безнең дә авылда,
нәкъ безнең урамда
бар шундый өч батыр:
«йодрыклары
чүлмәк-чүлмәк»,
чәчләре
кырып алынган,
башлары тап-такыр.
Әлбәттә, аларны
сез инде белмисез.
Сез безнең авылга
нигәдер килмисез.
Бар бездә өч Закир!
Килегез!
Күрерсез!

Аларга әбиләр:
– «Балакай!» – дип тора.
Һәр малай аларга:
– «Абыкай!» – дип тора,
елмаеп, кул биреп,
кунакка чакыра.
Бар бездә өч Закир,
өчәү тиң батырлар!
Һәркемгә билгеле –
янгынчы Закирлар!
Өч Закирның берсенә
бик рәхмәтле Гөлсинә.
Ул инде үсеп килә,
Гөлсинә инде белә.
Янгынчы Закир абый
уттан коткарган аны:
күреп янган зур өйне,
бәреп кергән ишекне.
Алып чыккан урамга
Гөлсинәле бишекне.
Өч Закирның икесе,
алары узган айны –
коткарганнар янудан
әби белән бабайны.

Узган елда өч Закир
чак янмаган үзләре:
коткарганнар янгыннан
сыерлар, үгезләрне,
сарыклар, бозауларны,
«Каравыл» дигән өйне,
ялгыш йокыга киткән
каравылчы кешене,
каравылчы янында
елап торган песине.

...Һәм,
озын сүзнең кыскасы,
озын сүзнең кыскасы
шул:
Закирларның һәрберсе дә,
барлык авыл кешесе дә,
олысы да, кечесе дә –
авылыбызда башка
янгын
булмаганын телиләр.
Җир шарында башка янгын
чыкмаганын телиләр.
Өч Закирның өч малае,
чүт-чүт кенә мактанчыклар:
– Үскәч янгын сүндерүче
булабыз! – дип йөриләр.





Матур көйләр көйлибез, Җырлыйбыз да биибез!

«Салават күпере» Казан шәһәре Вахитов районында урнашкан 273 нче татар балалар бакчасында кунакта булды. Анда тәрбияләнүче малай һәм кызларның кызыклы уеннарын, матур биюләрен күреп, соклануыбызны яшерә алмыйча, алар өчен чын күңелдән шатланып кайттык. Күчтәнәч итеп җибәргән җырлы-биюле уеннарын сезгә дә тәкъдим итәбез.

Утыр, утыр, Мәликә

Балалар түгәрәккә басалар. Бер бала, күзен бәйләп, түгәрәк уртасына утыра. Балалар, кулга-кул тотынып, түгәрәктә җырлап әйләнәләр:

Утыр, утыр, Мәликә, алмагачның төбенә,
Утыр, утыр, Мәликә, алмагачның төбенә,
Кем утырган каршыңа,
әйтеп бирче тиз генә.



Икенче бала аның каршысына килеп утыра. Уртадагы бала аны капшап белергә һәм исемен әйтергә тиеш. Әгәр белмәсә, аңа җәза бирелә. Уен шул рәвешчә дәвам итә.

Түбәтәй



Балалар түгәрәк ясап утыралар.

Түбәтәеңне кигәнсең,
Ераклардан килгәнсең.
Төскә матурлыгың белән,
Шак катырыйм дигәнсең.
Туп-туп түбәтәй,
Түбәтәең укалы.
Чиккән матур түбәтәең
Менә кемдә тукталды.

Көй барышында балалар түбәтәйне утырган килеш бер-берсенә тапшыралар. Җыр беткәч, түбәтәй кемдә кала, шуңа җәза бирелә. Уен шул рәвешчә дәвам итә.

Атлы



Балалар түгәрәк ясап басалар. Уртада «ат»ка атланган, кулына чыбыркы тоткан бала.

Кем безнең бик яхшы?
Кем безнең бик әйбәт?
Раил безнең бик яхшы,
Раил безнең бик әйбәт.
Раил атка атлана,
Ат шуңа шатлана.
Чыбыркыны селкетә,
Ат сикереп чабып китә.

Түгәрәк буенча «ат»ны чыбыркы белән куып әйләнеп йөри.

Ул йортка килеп җитә,
Матур кыз аны көтә.

«Ат»тан төшә, кыз янына килә, уртада бииләр.

Башмакчы



Башмакчы түгәрәк уртасында утыра, читек чигә.

Балалар әйләнеп җырлыйлар:

– Итек, читек, энә, без.
Матур читек тегәбез.
Башмак башын чигәбез.

Башмакчы:

– Кирәкмиме, алмыйсыз.
Әллә киеп карыйсыз.


Балалар, кулларын алга сузалар:

– Әй, башмакчы, башмакчы,
Үзе оста такмакчы.
Син сайрама такмагың,
Бир биергә башмагың.


Башмакчы үзе сайлап, бер бала янына килә:

– Әй, син, кыю-җитезме,
Мине куып тот әле.

Балалар түгәрәк тирәли әйләнеп куыша. Башмакчыга яки куучыга җәза бирелә.



Сканворд «Безнең гаилә»



Төзеде Гүзәл СӘЕТОВА.





Булат ИЛЬЯСОВ, 8 яшь.
Яшел Үзән.



Римма ГЫЙЛӘҖЕВА, 11 яшь.
Әлки, Түбән Әлки.

Журналга язылу бәясе – ярты елга 102 сум

Индексы– 73953



“САЛАВАТ КҮПЕРЕ”–

мәктәпкәчә яшьтәге балалар һәм кече яшьтәге укучылар өчен чыгарыла торган матур, акыллы,юмарт журнал.

Салават күпере

5(218) — 2008

Журнал 1990 елның март аеннан бирле чыга.
Журнал основан в 1990 году.
На татарском языке.

Баш мөхәррир урынбасары
Вакыйф НУРИЕВ

Баш мөхәррир урынбасары
Нәфис ИСХАКОВ

Җаваплы сәркатип
Ләбиб ЛЕРОН

Бизәлеш мөхәррире
Фәрит МУЛЛАХМӘТ

Компьютер дизайны
Мөнирә КУЗИЕВА

Исәп-хисап бүлеге
Рәмзия САЛИХ

Тышлыкта Фәрит МУЛЛАХМӘТ рәсемнәре.

Мәктәпкәчә яшьтәге һәм кече яшьтәге мәктәп балалары өчен.

«Салават күпере» журналының компьютер үзәгендә җыелды һәм төсләргә бүленде.

Басарга кул куелды 6.05.2008 ел.
Кәгазь форматы 60х90 1/8.
Гарнитура – Прагматика.
Офсет ысулы белән басыла.
Заказ Т-542.

Санны әзерләүчеләр:
З.Хәсният, В.Нуриев, Л.Лерон, Ф.Муллахмәт, М.Галиев, Н.Шаһиев, З.Вакказова, Г.Сабирова.



ЖУРНАЛНЫ ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ – «ТАТМЕДИА» АЧЫК АКЦИОНЕРЛЫК ҖӘМГЫЯТЕ.


Гомуми тираж 464920 данә
Тираж 11357 данә.

Баш мөхәррир
Зиннур ХӘСНИЯР

Безнең адрес:
420012 г.Казань, ул.Муштари, 14.
E-mail: salavatkupere@mail.ru

Татарстан Республикасы Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгы тарафыннан 96 нчы номер белән теркәлде.

«Идел-Пресс» ААҖ.
Казан, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.

Бәясе килешү буенча
Индекс 73953



Ләбиб ЛЕРОН

Яшел тантана

Күктә балкый май кояшы,
Сайрар кошлар җыр суза...
Күбәләктәй бөтерелә
Шат авазлар, чыр-чулар!

Бар да матур, бар да хозур:
Зәңгәр инеш... Су юлы...
Кыңгырау чәчкәләренең
Чың-чың итеп куюы...

Табигатьтә җыр агыла –
Сиреньнәрдән моң тама...
Бүген илдә – Май бәйрәме,
Җирдә – Яшел тантана!